ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 июль, 2026 ел № 8/10

Экологик экспертиза узарга тиешле
билгеләнгән хуҗалык һәм башка
эшчәнлек турында иҗтимагый фикер алышуны
оештыру һәм үткәрү тәртибен раслау хакында

«Экологик экспертиза турында» 1995 елның 23 ноябрендәге 174-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 47 статьясы 5 пункты, «Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү тәртибе турында» 2024 елның 28 ноябрендәге 1644 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Экологик экспертиза узарга тиешле билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында иҗтимагый фикер алышуны оештыру һәм үткәрү тәртибен кушымтага нигезләнеп расларга.

2. Шәһәр Советының «Экологик экспертиза узарга тиешле билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында иҗтимагый фикер алышуны оештыру һәм үткәрү тәртибен раслау хакында» 2024 елның 4 мартындагы 32/7 номерлы Карарын көчен югалткан дип танырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында 15.03.2024 урнаштырылган.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының
8/10 Карарына кушымта
29 июль, 2026 ел

Экологик экспертиза узарга тиешле билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында иҗтимагый фикер алышуны оештыру һәм үткәрү тәртибе

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге тәртип «Экологик экспертиза турында» 1995 елның 23 ноябрендәге 174-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ Федераль закон, «Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү материалларына таләпләрне раслау «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 47статьясы 5 пункты, «Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү тәртибе турында» 2024 елның 28 ноябрендәге 1644 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, шәһәр Уставы нигезендә эшләнгән һәм экологик экспертиза узарга тиешле билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында иҗтимагый фикер алышуны оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

2. Экологик экспертиза узарга тиешле билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында иҗтимагый фикер алышу (алга таба - иҗтимагый фикер алышу) билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү процессында җәмәгатьчелекнең катнашуын, җәмәгатьчелек фикерен ачыклауны һәм аны исәпкә алуны тәэмин итү максатларында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат җиткерүгә юнәлдерелгән.

3. Иҗтимагый фикер алышу объекты:

1) техник бирем проекты (заказчы техник биремне әзерләү турында карар кабул иткән очракта);

2) әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүнең башлангыч материаллары;

3) дәүләт экологик экспертизасы объекты яисә әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүнең башлангыч материаллары булган дәүләт экологик экспертизасы объекты (әгәр дә билгеләнгән хуҗалык эшчәнлеген һәм (яисә) башка эшчәнлекне нигезли торган документлар «Экологик экспертиза турында» 1995 елның 23 ноябрендәге 174-ФЗ номерлы Федераль законның 11 һәм 12 статьяларында каралганча дәүләт экологик экспертизасы объекты булсалар).

4. Иҗтимагый фикер алышуда катнашучылар:

1) билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек буенча документлар әзерләү өчен җаваплы, шул исәптән «Экологик экспертиза турында» 1995 елның 23 ноябрендәге 174-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек буенча документларны экологик экспертизага тапшыручы юридик яисә физик зат (алга таба – заказчы);

2) заказчы әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү буенча эшләр башкару хокукын биргән физик яисә юридик зат (алга таба - башкаручы);

3) хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре дәүләт экологик экспертизасы узарга тиешле билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлегенә кагыла яисә кагылырга мөмкин булган юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр;

4) иҗтимагый берләшмәләр һәм коммерциягә карамаган, дәүләтнеке булмаган башка оешмалар;

5) иҗтимагый фикер алышу уздыру көнендә 18 яшькә җиткән һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче, кызыксынган гражданнар.

5. Иҗтимагый фикер алышулар үзара дистанцион аралашу чараларын, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба – мәгълүмат системасы), Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтын (алга таба – рәсми сайт) кулланып уздырыла.

6. Гражданнар яисә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба — Башкарма комитет) инициативасы буенча иҗтимагый фикер алышу кысаларында (техник бирем проекты буенча иҗтимагый фикер алышудан тыш) иҗтимагый фикер алышу кара-каршы форматта җәмәгать тыңлаулары (алга таба – тыңлаулар) рәвешендә уздырыла.

7. Тыңлауларны уздыру инициативасы фикер алышулар объектын җәмәгатьчелеккә таныштыру өчен заказчы (башкаручы) тарафыннан урнаштырылганнан соң җиде календарь көн дәвамында (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 28 ноябрендәге 1644 номерлы карары белән расланган әйләнә - тирә мохиткә йогынтыны бәяләүне уздыру кагыйдәләренең 31 пунктындагы «а» пунктчасының өченче - бишенче абзацларында каралган очракларда – бер эш көне дәвамында), Башкарма комитетка гражданнар тарафыннан тиешле инициативаны ирекле рәвештә түбәндәге формадаларда җибәрү юлы белән тәкъдим ителергә мөмкин:

1) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайт (техник мөмкинлеге булганда) яисә мәгълүмат системасы (булганда) аша;

2) иҗтимагый фикер алышу уздыру турында хәбәрнамәдә (алга таба - фикер алышулар турында хәбәрнамә) күрсәтелгән адрес (адреслар) буенча Башкарма комитет адресына язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә.

8. Тыңлаулар уздыру турында инициатива керткәндә граждан түбәндәге белешмәләрне күрсәтә: фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туу датасы, яшәү урыны (теркәлгән урыны) адресы, телефоны, электрон почта адресы (булган очракта), шәхси өлкәсендәге Россия Федерациясе законнары нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы.

## 2 бүлек. Иҗтимагый фикер алышуны билгеләү тәртибе

9. Иҗтимагый фикер алышны оештыру һәм уздыру өчен заказчы (башкаручы) фикер алышу объектын урнаштыру планлаштырылган көнгә кадәр биш эш көненнән

дә соңга калмыйча Башкарма комитетка йогынты ясауны бәяләү кагыйдәләренең 24 пункты нигезендә фикер алышу турында хәбәрнамә тапшыра.

10. Заказчы (башкаручы) фикер алышу турында хәбәрнамәне электрон документ рәвешендә, шул исәптән рәсми сайт (техник мөмкинлеге булганда) яки мәгълүмат системалары (булганда) аша, яисә Башкарма комитетның электрон почтасы адресына kancel.chelny@tatar.ru җибәрә яки башка ысул белән тапшыра.

11. Башкарма комитет фикер алышу турында хәбәрнамәдә йогынтыны бәяләү кагыйдәләренең 26 пункты нигезендә өстәмә мәгълүмат күрсәтә.

12. Дәүләт экологик экспертизасы объекты яисә әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүнең башлангыч материаллары булган дәүләт экологик экспертизасы объекты фикер алышулар объекты булган очракта, тыңлаулар уздыру турында Башкарма комитет үз инициативасы белән карар кабул иткәндә, мондый тыңлауларны уздыру датасы заказчы (башкаручы) объектны җәмәгатьчелеккә таныштыру өчен урнаштырган көннән алып кимендә ун календарь көннән соңрак, фикер алышулар тәмамлану датасына кадәр ун календарь көннән дә соңга калмыйча билгеләнә.

13. Башкарма комитет әлеге Тәртипнең 9 пункты нигезендә фикер алышу турында хәбәрнамә кергән көннән алып ике эш көне эчендә аны:

1) «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтта;

2) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 19 мартындагы 329 номерлы карары белән расланган әйләнә-тирә мохитнең федераль дәүләт мәгълүмат системасы турында нигезләмәгә 28 нче кушымта нигезендә әйләнә-тирә мохитнең федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыра.

14. Гражданнарның тыңлаулар үткәрү турында инициативасы Башкарма комитетка кергән очракта, Башкарма комитет, йогынтыны бәяләү Кагыйдәләренең 23 пунктындагы җиденче һәм сигезенче абзацларын исәпкә алып, аны үткәрү датасын, вакытын, урынын билгели һәм мондый инициатива кергән көннән алып ике эш көне эчендә тыңлаулар турында хәбәрнамә урнаштыра (бастырып чыгара).

## 3 бүлек. Иҗтимагый фикер алышу уздыру тәртибе

15. Иҗтимагый фикер алышу объектын урнаштыру вакыты йогынтыны бәяләү Кагыйдәләренең 31 пункты нигезендә билгеләнә.

16. Фикер алышу объекты белән турыдан-туры танышу мөмкинлеге заказчы (башкаручы) тарафыннан фикер алышу турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән фикер алышу объекты урнашкан һәм аның белән турыдан-туры танышу мөмкин булган урын, фикер алышу объектыннан файдалану мөмкинлегенең башлану датасы, аннан файдалану вакыты, фикер алышу объекты белән танышу мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турындагы мәгълүмат нигезендә мондый объектны урнаштыру чорында тәэмин ителә.

17. Фикер алышу объекты белән турыдан-туры танышу өчен файдалана алырлык урында (урыннарда) Башкарма комитет әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендә иҗтимагый фикер алышуда катнашучыларның исәпкә алу, аларның искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен теркәү журналы булуын тәэмин итә. Әлеге журналга язмалар фикер алышу объекты белән танышкан иҗтимагый фикер

алышуда катнашучылар тарафыннан языла.

18. Фикер алышу объектын урнаштыру чоры дәвамында иҗтимагый фикер алышуда катнашучылар мондый фикер алышу объектына кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне түбәндәге ысуллар белән кертергә хокуклы:

1) рәсми сайт (техник мөмкинлеге булганда) яисә мәгълүмат системалары (булганда) аша;

2) тыңлаулар барышында язмача яисә телдән (тыңлаулар үткәрелгән очракта);

3) язма рәвештә яисә Башкарма комитет адресына җибәрелгән электрон документ рәвешендә;

4) фикер алышу объекты белән турыдан-туры танышучы иҗтимагый фикер алышуда катнашучыларны, аларның искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен исәпкә алу журналына теркәү юлы белән.

19. Иҗтимагый фикер алышуда катнашучы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр керткәндә түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

1) физик затлар өчен - фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туу датасы, яшәү (теркәлү) урыны адресы, телефоны, электрон почта адресы (булган очракта);

2) юридик затлар өчен - иҗтимагый фикер алышуда катнашучының тулы һәм кыскартылган исеме, төп дәүләт теркәве номеры, булган урыны чикләрендәге адресы, телефоны, электрон почта адресы (булган очракта), иҗтимагый фикер алышуда катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), вазыйфасы;

3) шәхси белешмәләр өлкәсендәге Россия Федерациясе законнары нигезендә шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык;

4) иҗтимагый фикер алышу беркетмәсен имзалауда катнашуга ризалык.

20. Иҗтимагый фикер алышуда катнашучыларның барысы да, фикер алышулар турындагы хәбәрнамә нигезендә, фикер алышу объектыннан бертигез файдалана ала, шул исәптән җәмәгать фикер алышуы үткәргәндә «Интернет» челтәрендә заказчы (башкаручы) тарафыннан фикер алышу объекты күрсәтелгән материалларны урнаштыру урыныннан.

## 4 бүлек. Иҗтимагый фикер алышуны җәмәгать тыңлаулары формасында үткәрү тәртибе

21. Җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм уздыру максатларында Башкарма комитет тыңлауларны уздыру буенча комиссия төзи. Комиссия составы тыңлаулар уздыруны билгеләү турында Башкарма комитет карары белән раслана.

22. Җәмәгать тыңлаулары башланыр алдыннан җәмәгать тыңлауларында катнашучылар җәмәгать тыңлауларында катнашучыларны исәпкә алу ведомостендә әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә теркәлергә тиеш. Җәмәгать тыңлауларында катнашучыларны теркәү җәмәгать тыңлаулары башланырга кимендә 30 минут кала башлана.

23. Җәмәгать тыңлауларында катнашучыларны теркәү вакытында физик затлар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлү белән шәхесне раслаучы документ күрсәтәләр.

24. Теркәлмәгән затлар җәмәгать тыңлауларына кертелми.

25. Җәмәгать тыңлаулары комиссиясе рәисе:

1) җәмәгать тыңлауларын ача, аның темасын һәм көн тәртибен игълан итә, җәмәгатьчелеккә заказчыны (башкаручыны) тәкъдим итә;

2) җәмәгать тыңлауларын уздыру регламентын тәкъдим итә;

3) җәмәгать тыңлауларын алып бара, тыңлаулар үткәрү регламентының үтәлешен күзәтүдә тота;

4) җәмәгать тыңлауларына йомгак ясый;

5) җәмәгать тыңлаулары уздыру максатларында башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

26. Җәмәгать тыңлаулары процедурасына түбәндәгеләр керә:

1) заказчы, проектчы, җәмәгать тыңлаулары инициаторы вәкилләренең докладлары;

2) җәмәгать тыңлаулары темасы буенча җәмәгать тыңлауларында катнашучыларның фикерләрен белдергән чыгышлары;

3) җәмәгать тыңлаулары темасы буенча кергән сорауларга җаваплар.

27. Җәмәгать тыңлауларында катнашучыларга чыгыш ясау өчен бирелә торган вакыт, шулай ук сораулар һәм аларга җаваплар бирү тәртибе җәмәгать тыңлаулары регламенты белән билгеләнә һәм җәмәгать тыңлауларында катнашучыларның барысына да игълан ителә.

28. Чыгыш ясар алдыннан җәмәгать тыңлауларында катнашучы үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен, шулай ук, әгәр чыгыш ясаучы нинди дә булса оешма вәкиле булса, вазыйфаи хәлен хәбәр итәргә тиеш.

29.Барлык докладчылар һәм җәмәгать тыңлауларында катнашучылар чыгышыннан соң заказчының һәм (яисә) башкаручының компетентлы белгечләре җавап бирә.

26. Барлык теләүчеләр чыгыш ясаганнан һәм җәмәгать тыңлауларында катнашучыларның сорауларына җавап биргәннән соң, җәмәгать тыңлаулары рәисе (тыңлаулар уздыру буенча эш төркеме рәисе) җәмәгать тыңлауларына төп йомгаклар ясый, беркетмәне әзерләү, аңа кул кую, кисәтүләр бирү тәртибен аңлата.

## 5 бүлек. Иҗтимагый фикер алышу йомгакларын рәсмиләштерү

31. Иҗтимагый фикер алышуны тәмамлау датасы булып заказчы (башкаручы) тарафыннан әлеге Тәртипнең 15 пункты нигезендә фикер алышу объектын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру датасы санала.

32. Башкарма комитет иҗтимагый фикер алышу тәмамланганнан соң биш эш көне эчендә иҗтимагый фикер алышу беркетмәсен рәсмиләштерә, беркетмә, рәсмиләштергән көннән алып, өч эш көне эчендә Комиссия рәисе, заказчы (башкаручы) вәкиле, әлеге Тәртипнең 19 пунктында күрсәтелгән иҗтимагый фикер алышуда катнашучылар тарафыннан имзалана, Башкарма комитет мөһере белән таныклана. Иҗтимагый фикер алышу беркетмәсе кәгазьдә рәсмиләштерелә.

Беркетмәдә мәгълүмат йогынтыны бәяләү Кагыйдәләренең 41 пункты нигезендә күрсәтелә.

33. Башкарма комитет иҗтимагый фикер алышу беркетмәсенә барлык затлар кул куйган көннән алып бер эш көне эчендә заказчыга (башкаручыга) фикер алышу турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән заказчының (башкаручының) контакт мәгълүматларыннан файдаланып, мондый хәбәрнамәнең җибәрелү фактын раслый торган ысул белән беркетмәгә имза салу турында хәбәр итә.

34. Фикер алышу объектына кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр керткән иҗтимагый фикер алышуда катнашучы, әгәр аның әлеге Тәртипнең 36 пункты нигезендә иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре белән танышырга техник мөмкинлеге булмаса, иҗтимагый фикер алышу беркетмәсеннән үзе керткән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр булган өземтәне Башкарма комитетта алырга хокуклы.

35. Иҗтимагый фикер алышуда катнашучыларның искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен карау нәтиҗәләре заказчы (башкаручы) тарафыннан искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алу таблицасында чагылдырыла. Искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләрен үз эченә алган искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алу таблицасы заказчы (башкаручы) тарафыннан иҗтимагый фикер алышу тәмамлану датасыннан соң бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча Башкарма комитетка бер яки берничә адрес буенча электрон документ рәвешендә тапшырыла, шул исәптән фикер алышулар турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча да.

36. Иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат (фикер алышулар беркетмәсе, кушымталар һәм искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алу таблицасы белән) Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелгән беркетмәгә имза салынган көннән алып бер эш көне эчендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 19 мартындагы 329 номерлы карары белән расланган әйләнә-тирә мохитнең федераль дәүләт мәгълүмат системасы турында Нигезләмәгә 28 нче кушымта нигезендә әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасына урнаштырыла.

37. Иҗтимагый фикер алышу беркетмәсенә карата искәрмәләр булган очракта, фикер алышуның, шул исәптән тыңлауларның заказчысы (башкаручысы) һәм (яисә) катнашучысы беркетмә урнаштырылган көннән алып биш эш көне эчендә беркетмәдә җибәрелгән төгәлсезлекләргә һәм (яисә) белешмәләрнең тулы булмавына күрсәтелгән гариза белән Башкарма комитетка ук ирекле формада мөрәҗәгать итәргә хокуклый:

1) рәсми сайт (техник мөмкинлеге булганда) яисә мәгълүмат системалары (булганда)аша;

2) фикер алышулар турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән адрес (адреслар) буенча Башкарма комитет адресына язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә.

38. Башкарма комитет кергән кисәтүләрне карый һәм аларны карау йомгаклары буенча, әлеге Тәртипнең 37 пунктының беренче абзацында күрсәтелгән гариза кергән көннән алып биш эш көне эчендә, гаризаны канәгатьләндерү турында һәм анда күрсәтелгән төгәлсезлекләрне һәм (яисә) тулы булмаган белешмәләрне төзәтү турында карар кабул итә, яисә, мондый гаризаны канәгатьләндерүдән баш

тарту турында дәлилле карар кабул итә, мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән рәвеш белән мәгълүмат бирә.

39. Башкарма комитетның әлеге Тәртипнең 37 пунктының беренче абзацында күрсәтелгән гаризаны канәгатьләндерүдән баш тарту турындагы карары белән килешмәгән очракта, заказчы (башкаручы) һәм (яисә) иҗтимагый фикер алышуда катнашучы мондый карарга Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерергә хокуклы.

Экологик экспертиза узарга тиешле билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында иҗтимагый фикер алышуны оештыру һәм үткәрү тәртибенә 1 кушымта

Иҗтимагый фикер алышуда катнашучыларны исәпкә алу ведомосте

Иҗтимагый фикер алышу объекты исеме: ____
Иҗтимагый фикер алышу уздыру чоры: ___
Җәмәгать тыңлауларын уздыру урыны: __
Җәмәгать тыңлауларын үткәрү датасы һәм вакыты: __

Физик затлар өчен:

| № т/б | фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) | туган көне | яшәү (теркәлү) урыны адресы | электрон почта адресы (булган очракта); телефоны | шәхси мәгълүматлар өлкәсендәге Россия Федерациясе законнары нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык | иҗтимагый фикер алышулар беркетмәсен имзалауга ризалык |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

Юридик затлар өчен:

| № т/б | тулы һәм кыскартылган (булган очракта) исеме | төп дәүләт теркәве номеры | урнашу урыны адресы | электрон почта адресы (булган очракта); телефон | иҗтимагый фикер алышуда катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), вазыйфасы | шәхси мәгълүматлар өлкәсендәге Россия Федерациясе законнары нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык | иҗтимагый фикер алышулар беркетмәсен имзалауга ризалык |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |

Экологик экспертиза узарга тиешле билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында иҗтимагый фикер алышуны оештыру һәм үткәрү тәртибенә 2 кушымта

ИСКӘРМӘЛӘРНЕ ҺӘМ ТӘКЪДИМНӘРНЕ ТЕРКӘҮ ЖУРНАЛЫ

Иҗтимагый фикер алышу объекты исеме: ____
Иҗтимагый фикер алышу уздыру чоры: ___

Физик затлар өчен:

| № т/б | фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) | туган көне | тшәү (теркәлү) урыны адресы | электрон почта адресы (булган очракта); телефоны | шәхси мәгълүматлар өлкәсендәге Россия Федерациясе законнары нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык | иҗтимагый фикер алышулар беркетмәсен имзалауга ризалык |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

Юридик затлар өчен:

| № т/б | тулы һәм кыскартылган (булган очракта) исеме | төп дәүләт теркәве номеры | урнашу урыны адресы | электрон почта адресы (булган очракта); телефон | иҗтимагый фикер алышуда катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), вазыйфасы | шәхси мәгълүматлар өлкәсендәге Россия Федерациясе законнары нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык | иҗтимагый фикер алышулар беркетмәсен имзалауга ризалык |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |